Республика Татарстан

Совет Менделеевского муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль районы Советы

РЕШЕНИЕ
03.10.2022 ел

Менделеевск ш.

КАРАР
№143

Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында

Социаль гарантияләрне тәэмин итү, муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләүче затларга, контроль-хисап органы рәисе, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләүне тәртипкә салу һәм камилләштерү максатларында, «Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыкларының урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» 2022елның 22 августындагы 881 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә.

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының «Депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы, муниципаль хезмәткәрләрнең, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 17 апрелендәге 142 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль берәмлек башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары

урынбасарларының, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының муниципаль берәмлекләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган айлык акчалата түләү күләмнәрен, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен 2022 елның 1 октябреннән 1,04 тапкырга арттырырга.

2. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Советының 2017 елның 17 апрелендәге 142 номерлы «Депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының үз вәкаләтләрен даими нигездә башкаручы, муниципаль хезмәткәрләрнең, Менделеевск муниципаль районы муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау турында» карары белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен аларның биләгән муниципаль хезмәт вазыйфалары окладлары күлмнәрен 2022 елның 1 октябреннән арттырырга.

3. Әлеге карарның 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләп чыгару өчен

Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләмен 1,04 мәртәбә индексацияләргә һәм аны 11 958 сум күләмендә билгеләргә.

4. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru /.

6. Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

Совет рәисе Р.И.Беляев